**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

08.06.2022 № 186

**Татарстан Республикасында «Президент Академиясенең җәйге кампусы» унынчы халыкара мәгърифәти форумын уздыру турында**

Инициативалы, иҗат белән шөгыльләнүче студент-яшьләргә ярдәм итү максатларында, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе мөрәҗәгатен истә тотып:

1. 2022 елның 13 июленнән 26 июленә кадәр Татарстан Республикасында «Казан» тау чаңгысы спорт-савыктыру комплексы» акционер җәмгыяте базасында һәм Иннополис шәһәрендә 210 студент катнашачак «Президент Академиясенең җәйге кампусы» унынчы халыкара мәгърифәти форумын уздырырга.

2. Татарстан Республикасында «Президент Академиясенең җәйге кампусы» унынчы халыкара мәгърифәти форумын оештыру һәм уздыру буенча ведомствоара эш төркемен оештырырга һәм кушымта нигезендә аның составын расларга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге боерыкны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче карарлар кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Президентының
2022 елның «08» июнендәге
186 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасында «Президент Академиясенең җәйге кампусы» унынчы халыкара мәгърифәти форумын оештыру һәм уздыру буенча ведомствоара эш төркеме составы**

| | |
|---|---|
| Сәфәров Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, эш төркеме рәисе |
| Терентьев Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе, эш төркеме рәисе урынбасары |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры, эш төркеме рәисе урынбасары |
| Әюпова Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Бәхтияров Тимур Александрович | «Президент Академиясенең җәйге кампусы» унынчы халыкара мәгърифәти форумы башкарма директоры (килешү буенча) |
| Галиев Инсаф Мөшәррәф улы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы |
| Зыятдинов Марат Галимҗан улы | «Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |

| | |
|---|---|
| Мәхмүтов<br>Илдар Сәйфулла улы | «Казан» тау чаңгысы спорт-савыктыру комплексы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Мөхәммәтҗанов<br>Фәргать Усман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы полиция башлыгы урынбасары (җәмәгать тәртибен саклау буенча) (килешү буенча) |
| Садыйков<br>Марат Наил улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Сәлимгәрәев<br>Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Семенихин<br>Кирилл Владимирович | «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Сөләйманов<br>Тимур Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Федотов<br>Иван Владимирович | «Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе проректоры, «Россиянең инновацияле төбәкләре ассоциациясе» Россия Федерациясе субъектларының икътисадый хезмәттәшлеге ассоциациясе директоры (килешү буенча) |
| Хәбибуллин<br>Рафис Җәүдәт улы | Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәйруллин<br>Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |

| | |
|---|---|
| Хәлимов<br>Ренат Азат улы | «Иннополис» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәнифов<br>Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Шаһалиев<br>Руслан Ринат улы | Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге мэры – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шаһиәхмәтов<br>Мидхәт Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры |

___________